| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА ЯКУШКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯКУШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

Якушкино
ав.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08 » ноябрь 2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 22 ноярендә Абрыскино авылы, Гагарин урамы, 89нчы йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылы гражданнары җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Абрыскино авылы территориясендә теркәлгән, яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентларның тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми

сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Абрыскино авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х. Хәмидуллин